ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Зур Кызыл ур. 15/9, Казан ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 479

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«25.» 12. 2019 ел

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең норматив хокукый актларын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына (алга таба – Регламент), аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Юридик бүлек башлыгы (Воронская Н.Н.) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык С.А.Крайнов

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2019 елның 25.12. 479 номерлы боерыгы редакциясендә) белән расланды

# Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламенты (алга таба – Административ регламент) Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең тәртибен һәм стандартын билгели.

Административ регламентта шулай ук административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, аларны үтәү эзлеклелеге һәм сроклары билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеге лицензияләнергә тиеш.

1.2. Гариза бирүчеләр булып:

- күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру нияте булган яки гамәлгә ашыра торган юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар (алга таба тиешенчә – лицензия алырга теләгән зат, лицензиат);

- физик һәм юридик затлар, лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга конкрет лицензия турында белешмәләр һәм (яки) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча башка мәгълүмат алу нияте булган физик затлар яки юридик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе (алга таба – ТР Дәүләт торак инспекциясе) тарафыннан күрсәтелә.

ТР Дәүләт торак инспекциясе урнашкан урын: Казан шәһәре, З.Кызыл урамы, 15/9 йорт.

ТР Дәүләт торак инспекциясенең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 8.30 сәгатьтән алып 17.30 сәгатькә кадәр, җомга: 8.30 сәгатьтән алып 16.15 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Җәмәгать транспортында «Ирек мәйданы» тукталышына кадәр килергә:

- 10а, 22, 28, 28а, 30, 35, 54, 63, 89; 91, 98 санлы автобуслар;
- 2, 3, 5, 7, 8 санлы троллейбуслар;
- метро (иң якыны – «Кремль станциясе»).

Кертү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә. Белешмә телефоны: (843) 590-88-71.

Документларны кабул итү ТР Дәүләт торак инспекциясенең эш графигы

нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.3.1. Лицензияләүне гамәлгә ашыручы бүлек (алга таба – Бүлек) хезмәткәренең белешмә телефоны: 590-88-71.

1.3.2. ТР Дәүләт торак инспекциясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: https://gji.tatarstan.ru.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында, шулай ук ТР Дәүләт торак инспекциясенең урнашкан урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат бирү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасында урнашкан, дәүләт хезмәте турындагы мәгълүматларны үз эченә алган мәгълүмат стендлары аша. Стендлардагы мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла, әлеге Административ регламентның 1.1, 1.3, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1, 5.2 пунктларында булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):

ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында (https://gji.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

ТР Дәүләт торак инспекциясенә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

ТР Дәүләт торак инспекциясенә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә (электрон почта адресы: tatgi@tatar.ru).

1.4.1. ТР Дәүләт торак инспекциясенең урнашкан урыны, белешмә телефоны, эш графигы, рәсми сайтының адресы, шулай ук электрон почтасы турында мәгълүмат ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында, ТР Дәүләт торак инспекциясенең гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында Бүлек белгече тарафыннан урнаштырыла.

1.5. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Салым кодексы (алга таба – РФ Салым кодексы)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1998, №31, 3824 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба – РФ Торак кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, №1, 14 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, №52, 6249 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында» 2009 елның 9

февралендәге 8-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2009, № 7, 776 статьясы, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №31, 4179 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 99-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №19, 2716 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы (алга таба – РФ Президентының 601 номерлы указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, №19, 2338 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Лицензиянең үрнәк формасын раслау турында» 2011 елның 6 октябрендәге 826 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 2011 елның 6 октябрендәге 826 номерлы карар) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №42, 5924 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләүне оештыру турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 957 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №48, 6931 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү турында» 2014 елның 28 октябрендәге 1110 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмә (алга таба – 1110 номерлы нигезләмә) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, №44, 6074 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын, лицензия контроле буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламентын, күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләгәндә кулланыла торган документларның формаларын эшләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2014 елның 28 октябрендәге 657/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгының 2014 елның 28 октябрендәге 657/пр номерлы боерыгы) («Нормирование в строительстве и ЖКХ», № 5, 2014);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары

норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, №46, 2144 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, №10, 0383 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.6. Административ регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәре яки муниципаль районы (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Административ регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты). Гаризаларның рәвешләре әлеге Регламентның 1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче кушымталарында китерелде.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәтне яки таләпне билгеле торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү | 99-ФЗ номерлы федераль закон;<br>РФ Торак кодексы |
| 2.2. Башкарма хакимият органы исеме | Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе (алга таба – ТР Дәүләт торак инспекциясе) | Нигезләмәнең 1.1 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | а) лицензия бирү (бирүдән баш тарту);<br>б) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү (үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту);<br>в) лицензия алырга теләгән зат, лицензиат турында лицензияләр реестрына кертелгән белешмәләр;<br>г) лицензия дубликатын бирү;<br>д) лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә конкрет лицензия турында белешмәләр, кабул ителгән карар турында ТР Дәүләт торак инспекциясе акты күчермәсен яки сорала торган белешмәләрнең булмавы турында белешмә бирү;<br>е) лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату яки лицензияне гамәлдән чыгару турында карар | 99-ФЗ номерлы федераль законның 14, 17, 18, 20, 21 статьялары;<br>РФ Торак кодексының 194, 199, 200 статьялары |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга | а) ТР Дәүләт торак инспекциясенә лицензия бирү турында лицензия алырга теләүче затның гаризасын һәм аңа теркәлгән документларны карау – лицензия бирү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гаризаны һәм әлеге | РФ Торак кодексының 194 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Регламентның 2.5 пунктында каралган, аңа теркәлә торган документларны (белешмәләрне) тулы күләмендә кабул иткән көннән башлап 30 (утыз) эш көне; | |
| | б) лицензия бирү (лицензия бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү – Татарстан Республикасы лицензия комиссиясенә ТР Дәүләт торак инспекциясенә лицензия бирү турында яки аны бирүдән баш тарту турында нигезләнгән тәкъдим килгән көннән башлап 4 (дүрт) эш көне; | 99-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясы;<br>РФ Торак кодексының 201 статьясы;<br>1110 номерлы карарның 10 пункты |
| | в) лицензия бирү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы лицензия комиссиясе карары кабул ителгәннән соң 2 эш көне эчендә чыгарыла; | |
| | г) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында (үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында) карар кабул итү (үзгәртеп кору формасында юридик затны үзгәрткән, аның исемен, урнашкан урыны адресын үзгәрткән очракларда, шулай ук шәхси эшкуарның яшәгән урыны, исеме, фамилиясе һәм (булган очракта) атасының исеме, аның шәхесен таныклый торган документ реквизитлары үзгәртелгән очракта) – ТР Дәүләт торак инспекциясенә лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, аңа теркәлә торган документлар (белешмәләр) тулы күләмендә килгән көннән башлап 10 (ун) эш көне; | 99-ФЗ номерлы федераль законның 18 статьясы |
| | д) лицензия бирү (тапшыру) - лицензиягә кул | 99-ФЗ номерлы федераль |

| | | |
|---|---|---|
| | куелганнан соң һәм лицензияләр реестрында теркәлгәннән соң 3 эш көне;<br><br>е) лицензия дубликаты бирү – гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документлар ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән датадан башлап 3 эш көне; | законның 14 статьясы<br><br>99-ФЗ номерлы федераль законның 17 статьясы |
| | ж) лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә конкрет лицензия турында белешмәләр, кабул ителгән карар турында акт күчермәсе яки сорала торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәр итү – документ (гариза) ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән датадан башлап 5 эш көне;<br><br>з) лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату һәм лицензияне гамәлдән чыгару – лицензияне гамәлдән чыгару турында законлы көченә кергән суд карары (законлы көченә кергән суд карарыннан өземтә) ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән көннән башлап 10 эш көне эчендә<br><br>и) лицензиянең гамәлдә булу вакытын озынайту турында (лицензиянең гамәлдә булу вакытын озынайтудан баш тарту турында) карар кабул итү – гариза ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән датадан башлап 30 календарь көне.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ (лицензияне бирүдән тыш) гариза бирүче мөрәҗәгать иткән | 99-ФЗ номерлы федераль законның 21 статьясы<br><br>99-ФЗ номерлы федераль законның 20 статьясы<br><br>1110 номерлы карарның 17 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | көнне бирелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта буенча яки электрон адреска) җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла (лицензияне җибәрүдән тыш). | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Лицензия алу өчен түбәндәге документлар (белешмәләр) тапшырыла:<br>а) лицензия бирү турында гариза, 99-ФЗ номерлы федераль законның 13 статьясының 1 өлешендә каралган белешмәләрне һәм лицензия алырга теләүче затның 1110 номерлы нигезләмәнең 4 пунктында билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килүе турында белешмәләрне (1 нче кушымта) күрсәтеп;<br>б) лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының (юридик затның бер кулдагы башкарма органының, юридик зат җитәкчесенең яки аның филиалы җитәкчесенең яки шәхси эшкуарның) квалификация аттестаты күчермәсе;<br>в) лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының вазыйфага билгеләнүе турында боерык күчермәсе;<br>г) теркәлә торган документлар исемлеге.<br>2. Юридик затны үзгәртү формасында үзгәртеп корылган очракларда лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү өчен түбәндәге документлар (белешмәләр) тапшырыла:<br>а) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштергән өчен дәүләт пошлинасы түләнүен раслаучы документ реквизитларын, лицензиат яки аның хокукый варисы турында 99-ФЗ | 99-ФЗ номерлы федераль законның 13, 17, 18, 20, 21 статьялары;<br>1110 номерлы карарның 5, 6 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | номерлы федераль законның 13 статьясының 1 өлешендә каралган яңа белешмәләрне һәм юридик затларның бердәм дәүләт реетрына тиешле үзгәрешләрнең кертелү фактын раслаучы документ белешмәләрен күрсәтеп. Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүгә нигез булган очрак (2 нче кушымта) барлыкка килгән көннән башлап 15 эш көненнән соңга калмыйча ТР Дәүләт торак инспекциясенә тапшырыла;<br>б) гамәлдәге лицензиянең төп нөсхәсе;<br>в) теркәлә торган документлар исемлеге.<br>3. Юридик затның атамасы, аның урнашкан урынының адресы үзгәргән очракларда, шулай ук шәхси эшкуарның яшәгән урыны, исеме, фамилиясе һәм атасының исеме (булган очракта), аның шәхесен таныклый торган документ реквизитлары үзгәртелгән очракларда түбәндәге документлар (белешмәләр) тапшырыла:<br>а) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштергән өчен дәүләт пошлинасын түләгәнлекне раслаучы документ реквизитларын, лециат турында яңа белешмәләрне һәм юридик затларның бердәм дәүләт реестрына (юридик зат лицензиаты өчен), шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына (лицензиат - шәхси эшкуар өчен) тиешле үзгәрешләр кертелү фактын раслаучы документ белешмәләрен күрсәтеп (3 нче кушымта);<br>б) гамәлдәге лицензиянең төп нөсхәсе;<br>в) теркәлә торган документлар исемлеге.<br>4. 99-ФЗ номерлы федераль законның 20 статьясының | |

| | | |
|---|---|---|
| | 13 өлешендәге 1 пунктында каралган очракта лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату өчен күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген туктату турында гариза тапшырыла, анда күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеге фактта туктатылган дата күрсәтелә.<br>5. Лицензия дубликатын алу өчен түбәндәге документлар тапшырыла:<br>а) лицензия дубликатын бирү турында гариза, анда лицензия дубликатын бирү өчен дәүләт пошлинасын түләү фактын раслый торган документ реквизитлары күрсәтелә (4 нче кушымта);<br>б) лицензиянең бозылган бланкы (лицензия бозылган очракта).<br>6. Лицензиянең гамәлдә булу вакытын озынайту өчен лицензиянең гамәлдә булу вакытын озынайту турында гариза тапшырыла.<br>7. Лицензияләр реестрыннан конкрет лицензия турында белешмәләр алу өчен физик заттан яки юридик заттан шундый белешмәләрне тапшыру турында гариза тапшырыла.<br>8. Лицензиядәге техник хатаны төзәтү өчен түбәндәге документлар (белешмәләр) тапшырыла:<br>а) техник хатаны төзәтү турында гариза (5 нче кушымта);<br>б) техник хатасы булган лицензиянең төп нөсхәсе;<br>в) техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар;<br>г) теркәлә торган документлар исемлеге.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча гариза кәгазен | |

| | | |
|---|---|---|
| | гариза бирүче ТР Дәүләт торак инспекциясенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазь документ рәвешендә түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин: шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);<br>кулга тапшыру турында белдереп, почта аша заказлы хат итеп.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түбәндәге документлар (белешмәләр) кирәк, алар түбәндәгеләр карамагында тора:<br>а) Федераль казначылык – дәүләт пошлинасын түләү турында белешмәләр;<br>б) Федераль салым хезмәте – Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында һәм Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләр;<br>в) Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы - лицензия алырга теләүченең вазыйфаи затында икътисад өлкәсендәге җинаятьләр, уртача авырлыктагы җинаятьләр, авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен алынмаган яки | 96-ФЗ номерлы федераль законның 18 статьясы;<br>1110 номерлы нигезләмәнең 9 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | үтәлмәгән суд хөкеме булуы (булмавы) турында белешмәләр;<br>г) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы – лицензия алырга теләүченең вазыйфаи заты турында лицензиясе гамәлдән чыгарылган лицензиатның бер кулдагы башкарма органы функцияләрен башкаручы затлар, шулай ук лицензиатның уставында яки башка документларында күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү буенча таләпләр үтәлеше өчен җаваплылык йөкләнгән һәм үзләренә карата квалификациясеннән мәхрүм итү кебек административ җәза кулланылган затлар, лицензиясе гамәлдән чыгарылган һәм (яки) үзләренә карата квалификациясеннән мәхрүм итү кебек административ җәза кулланылган шәхси эшкуарлар реестрында мәгълүматның булуы (булмавы) турында, шулай ук лицензияләрнең җыелма федераль реестрында лицензия алырга теләүчегә элегрәк бирелгән лицензияне гамәлдән чыгару турында мәгълүматларның булмавы турында белешмәләр.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Гариза бирүчедән:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат тапшыруны таләп итү тыела.<br>Гариза бирүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торган документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның гариза бирүче тарафыннан тапшырылмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны | Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре каралмаган | |

| | | |
|---|---|---|
| кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) лицензия бирүдән түбәндәге нигезләрдә баш тартыла:<br>а) гариза бирүче тапшырган лицензия бирү турындагы гаризада һәм (яки) башка документларда (белешмәләрдә) төгәл булмаган яки ялган мәгълүмат булганда;<br>б) тикшерү барышында лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә җавап бирмәве билгеләнгәндә;<br>2) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән түбәндәге нигезләрдә баш тартыла:<br>а) гариза бирүче тапшырган лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы гаризада һәм (яки) башка документларда (белешмәләрдә) төгәл булмаган яки ялган мәгълүмат булганда;<br>б) тикшерү барышында лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә җавап бирмәве билгеләнгәндә;<br>3) гариза бирүче булып тормаган зат гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, лицензия дубликаты бирүдән баш тартыла;<br>4) әгәр дәүләт серен яки хезмәт серен саклау мәнфәгатьләрендә Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый белешмәләрдән ирекле файдалану чикләнгән булса, лицензияләрнең бердәм реестрыннан мәгълүмат бирүдән баш тартыла | 99-ФЗ номерлы федераль законның 14, 18, 21 статьялары |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүле нигездә күрсәтелә.<br>Дәүләт пошлинасы:<br>күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия бирү – 30 000 сум;<br>күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү – 5 000 сум;<br>күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия дубликаты бирү (тапшыру) – 5 000 сум;<br>Түләүне алучы:<br>Татарстан Республикасы буенча Федераль казна идарәсе (ТР ДТИ)<br>Түләү реквизитлары:<br>Исәп-хисап счеты:<br>№ 40101810800000010001<br>Банк: БҮЛЕКЧӘ - ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МБ КАЗАН ШӘҺӘРЕ<br>Банк тәңгәллек коды: 049205001<br>Алучының тәңгәллек саны (61) - 1653015798<br>Алучы исәпкә алуның сәбәп коды (103) - 165501001<br>Бюджет классификация коды: 71410807400011000110<br>«Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләүгә бәйле вәкаләтле органнарның гамәлләре өчен дәүләт пошлинасы»<br>Муниципаль берәмлекләр территорияләренең россиякүләм классификаторы нигезендә ОКТМО.<br>Исәп-хисап документының «түләүнең билгеләнеше»(24) | 96-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясы;<br>РФ Салым кодексының 333.33 статьясының 1 пунктындагы 134 пунктчасы |

| | | |
|---|---|---|
| | юлында түләүнең билгеләнешен тәңгәлләштерү өчен кирәкле өстәмә башка мәгълүматларны күрсәтү рөхсәт ителә<br>«Түләүченең статусы» (101) юлы: 08 тутыру өчен мәҗбүри.<br>Конкрет лицензия турында белешмәләр физик һәм юридик затларга лицензияләр реестрыннан өземтә, яки кабул ителгән карар турында акт күчермәсе, яки сорала торган белешмәләрнең булмавы турында белешмә рәвешендә түләүсез бирелә. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Лицензия алырга теләгән зат (лицензиат) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм (яки) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы 15 минуттан артып китмәскә тиеш.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | РФ Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан хезмәт күрсәтү турында гариза бирүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Кирәкле барлык документлары белән гариза килгән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру үрнәкләре һәм | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Стендлардагы мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге тудырыла (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм анын | |

| | | |
|---|---|---|
| аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматны урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән, үзара бәйләнешкә кереп, эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасының җәмәгать транспортыннан файдалана алу мөмкинлеге булган зонада урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, ТР Дәүләт торак инспекциясенең «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат | |

| | | |
|---|---|---|
| барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән дә файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) яки | ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында тулы мәгълүмат булуы;<br>гаризаны ТР Дәүләт торак инспекциясенең Интернет челтәрендәге мәгълүмат ресурслары ярдәмендә электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;<br>инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулык итә торган каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән сыйфатлана:<br>документларны кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә тапшырганда – чиратларның;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү вакытлары бозылуның;<br>дәүләт хезмәтен күрсәткән граждан хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләрнең;<br>дәүләт хезмәте күрсәткән граждан хезмәткәрләренең гариза бирүчеләргә карата дорфа, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләрнең.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәте күрсәтә торган вазыйфаи зат белән гариза бирүче арасында бер мәртәбә хезмәттәшлек итү күздә тотыла. Үзара хезмәттәшлек итү озынлыгы әлеге Регламентта билгеләнә.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә | |

| | | |
|---|---|---|
| файдалана алмау мөмкинлеге | күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан ТР Дәүләт торак инспекциясенең http://www.gji.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен, шул исәптән экстерри-ториаль принцип буенча да (дәүләт хезмәте экстерри-ториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта), һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган башка таләпләр | Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны ТР Дәүләт торак инспекциясе сайты базасында булдырылган Интернет-кабул итү системасы ярдәмендә тапшырып, электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеге бар | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә түбәндәге административ процедуралар гамәлгә ашырыла:

1) лицензия бирү турында гаризаны, башка документларны карау һәм лицензия бирү турында (бирүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

2) техник хатаны төзәтү;

3) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гаризаны, башка документларны карау һәм лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында (үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

4) ТР Дәүләт торак инспекциясенең башка федераль дәүләт хакимияте органнары, ТР Лицензияләү комиссиясе һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнар белән үзара хезмәттәшлек итүе, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган әлеге органнарга җибәрү;

5) лицензия дубликаты бирү;

6) лицензияләр реестрыннан конкрет лицензия турында белешмәләр бирү турындагы гаризаны карау;

7) лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату;

8) лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гаризаны карау.

### Лицензия бирү турында гаризаны, башка документларны карау һәм лицензия бирү турында (бирүдән баш тарту турында) карар кабул итү

3.2. Гариза бирүчене консультацияләү.

3.2.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен ТР Дәүләт торак инспекциясенә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

ТР Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләүне гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи заты (алга таба – җаваплы башкаручы) гариза бирүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка сораулар буенча да.

Җаваплы башкаручы гариза бирүчене дәүләт хезмәтеннән файдалану предметы буенча консультацияли, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бланкын тапшыра һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм лицензия алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләү.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче (аның вәкиле) кәгазьдә, почта аша почта юлламасы

белән яки электрон рәвештә (шәхси эшкуарлар өчен), әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, гариза (1 нче кушымта) тапшыра (җибәрә).

3.3.2. ТР Дәүләт торак инспекциясенә гариза тапшырылганда җаваплы башкаручы:

гаризаны һәм башка документларны исемлек буенча кабул итә;

тикшерә:

- документларның тупланышын;

- гариза формасы нигезендә гаризада күрсәтелергә тиешле мәгълүматның (белешмәләрнең, күрсәткечләрнең) булуына карата гаризаны тутыру тулылыгын;

- тапшырылган гаризада күрсәтелгән мәгълүматларның (белешмәләрнең, күрсәткечләрнең) һәм тапшырылган документлар тупланмасында булган мәгълүматларның (белешмәләрнең, күрсәткечләрнең) туры килүен.

Җаваплы башкаручы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документ әйләнеше буенча бердәм ведомствоара системасында (алга таба – Электрон Хөкүмәт) теркәү өчен, гаризаны ТР Дәүләт торак инспекциясенең гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү һәм эш башкару бүлегенә тапшыра. Күрсәтелгән гаризаларны һәм документларны кабул итү датасы турында тамгалап, исемлек күчермәсен лицензия алырга теләүчегә, лицензиатка тапшыра яки, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар кирәкле барлык документлары белән гариза килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлүче документлары белән теркәүгә алынган гариза.

3.3.3. ТР Дәүләт торак инспекциясенә әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән гариза килгән очракта, җаваплы башкаручы аларны кабул итү көненнән соңгы 3 эш көне эчендә лицензия алырга теләгән затка, лицензиатка утыз көнлек срокта ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү зарурлыгы турында хәбәр (алга таба – җитешсезлекләрне бетерү турында хәбәр) бирә яки мондый хәбәрне, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә.

Ачыкланган җитешсезлекләрне бетерүнең утыз көнлек срогы лицензия алырга теләүченең, лицензиатның әлеге хәбәрне алуын документаль рәсмиләштергән датадан башлап санала.

Лицензия алырга теләгән зат, лицензиат утыз көнлек срокта гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны (белешмәләрне) тулы күләмендә тапшырмаган очракта, җаваплы башкаручы 3 эш көне эчендә лицензия алырга теләгән затка, лицензиатка гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны, кайтарып бирү сәбәпләрен дәлилле нигезләп, кайтарып бирә яки, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә.

Рәсмиләштерелгән гариза һәм аңа теркәлә торган документлар әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры китереп тулы күләмендә тапшырылган очракта, яисә җитешсезлекләрне бетерү турында

хәбәрдә күрсәтелгән җитешсезлекләр бетерелгәндә, җаваплы башкаручы гаризаны һәм документларны кабул иткән көннән башлап 3 эш көне эчендә лицензия алырга теләгән затка, лицензиатка, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып та, аларның ТР Дәүләт торак инспекциясенә карау өчен кабул ителүе турында хәбәр итә, лицензия алырга теләгән затка планнан тыш документар тикшерү уздыру турында боерык (күрсәтмә) проектын әзерли.

Процедураның нәтиҗәсе: җитешсезлекләрне бетерү турында хәбәр итү, гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны кайтару турында хәбәр итү, лицензия алырга теләүчегә, лицензиатка гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны кабул итү турында хәбәр итү, планнан тыш документар тикшерү уздыру турында боерык (күрсәтмә) проекты.

3.4. Җаваплы башкаручы тапшырылган документларның (белешмәләрнең) тулы һәм дөрес булуын тикшерә, – түбәндәгеләрне бәяләү максатында:

а) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән аерым документлар арасындагы мәгълүматларның килештерелгән булуын;

б) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү юлы белән лицензия алырга теләүче зат турында ТР Дәүләт торак инспекциясенә алынган белешмәләргә туры килүен.

Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү әлеге Регламентның 3.14 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсмиләштерелгән гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән көннән башлап 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын тикшерү акты.

3.5. Җаваплы башкаручы лицензия алырга теләгән затның лицензия таләпләренә җавап бирүе предметына планнан тыш документар тикшерү уздыру турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгын (күрсәтмәсен) әзерли, ул ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан имзалана.

Лицензия алырга теләүчегә карата планнан тыш документар тикшерү тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм документлар лицензияләүче органга килгән көннән башлап 20 эш көненнән артмаган срокта билгеләнгән тәртиптә прокуратура органнары белән килештермичә уздырыла.

Лицензия алырга теләүчегә лицензия таләпләренә җавап бирүенә карата планнан тыш документар тикшерү уздырганда түбәндәгеләр тикшерелергә тиеш:

а) Россия Федерациясе территориясендә лицензия алырга теләүченең юридик зат яисә шәхси эшкуар сыйфатында теркәлүе. Чит ил дәүләтләрендә теркәлгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга рөхсәт бирелми;

б) лицензия алырга теләгән затның фирма атамасының күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукы алданрак барлыкка килгән лицензиатның фирма атамасы белән охшаш булмавы

яисә бутау дәрәҗәсендә бер-берсенә туры килмәве;

в) лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затында (күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы юридик затның бер кулдагы башкарма органында, юридик зат җитәкчесендә яисә аның филиалында яисә шәхси эшкуарда, ә бер кулдагы башкарма орган вәкаләтләрен тапшыру турында килешү төзелгән очракта – мондый вәкаләтләр тапшырылган юридик затның бер кулдагы башкарма органында яисә шәхси эшкуарда) квалификация аттестатының булуы;

г) лицензия алырга теләүченең вазыйфаи затында икътисад өлкәсендәге җинаятьләр өчен, уртача авырлыктагы, авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен алынмаган яисә үтәлмәгән суд хөкеменең булмавы;

д) лицензиатның лицензиясе гамәлдән чыгарылган бер кулдагы башкарма орган функцияләрен гамәлгә ашыручы затлар, шулай ук лицензиат уставында яисә башка документларында күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәү өчен җаваплылык йөкләнгән һәм үзләренә карата квалификациясен алу рәвешендә административ җәза кулланылган затлар, лицензиясе гамәлдән чыгарылган һәм квалификациясен алу рәвешендә административ җәза билгеләнгән шәхси эшкуарлар реестрында лицензия алырга теләүченең вазыйфаи заты турында мәгълүматның булмавы;

е) күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләрнең җыелма федераль реестрында лицензиатка, лицензия алырга теләүчегә элегрәк бирелгән күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияне гамәлдән чыгару турында мәгълүмат булмавы.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм документлар ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән көннән башлап 20 эш көненнән артмаган срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: планнан тыш документар тикшерү уздыру акты.

3.6. Җаваплы башкаручы лицензия алырга теләүчегә планнан тыш документар тикшерүне төгәлләгән датадан башлап 2 эш көне эчендә, тапшырылган белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын тикшерү һәм планнан тыш документар тикшерү нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы лицензияләү комиссиясе өчен түбәндәгеләрне тәкъдим итеп материаллар әзерли:

а) лицензия бирү турында – лицензия бирүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында билгеләнгән нигезләр булмаган очракта;

б) лицензия бирүдән баш тарту турында – лицензия бирүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында билгеләнгән нигезләр булган очракта.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар лицензия алырга теләүчедән лицензия бирү турында яки лицензия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү максатында килгән тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм башка документлар теркәлгән датадан башлап 30 эш көне узганчы гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ТР лицензияләү комиссиясе өчен материаллар һәм тәкъдимнәр.

3.7. Татарстан Республикасының лицензияләү комиссиясе ТР Дәүләт торак инспекциясе җибәргән материалларны карый һәм, аның эшчәнлеге турындагы Нигезләмәгә туры китереп, карар чыгара.

Татарстан Республикасының лицензияләү комиссиясе карары кабул ителгән көненнән башлап 2 эш көне эчендә ТР Дәүләт торак инспекциясенә җибәрелә.

Процедураның нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы лицензияләү комиссиясе карары.

3.7.1. Лицензия бирү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы лицензияләү комиссиясеннән карар алынган көннән башлап 2 эш көне эчендә чыгарыла.

Лицензия бирү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы һәм лицензия бер үк вакытта ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгы тарафыннан имзалана һәм лицензияләр реестрында теркәлә.

Лицензия бирү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгында һәм лицензиядә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) лицензияләүче органның атамасы – ТР Дәүләт торак инспекциясе;

б) юридик затның тулы һәм (булган очракта) кыскартылган атамасы, шул исәптән фирма исеме, оешу-хокук формасы, аның урнашкан урыны адресы, лицензияләнә торган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру урыннары адреслары, юридик зат оештыру турында язуның дәүләт теркәвенә алу номеры;

в) салым түләүченең тәңгәллек номеры;

г) лицензияләнә торган эшчәнлек төре – күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеге;

д) лицензиянең номеры һәм теркәү датасы;

е) боерык номеры һәм датасы.

Лицензия катгый хисаплылыктагы һәм ялганлап ясаудан полиграфия продукциясе белән якланган ТР Дәүләт торак инспекциясе бланкында әлеге Регламентка 6 нчы кушымтага туры китерелгән форма буенча рәсмиләштерелә.

Лицензиягә имза салынган һәм ул теркәүгә алынган көннән башлап 2 эш көне эчендә җаваплы башкаручы лицензияне гариза бирүчегә (Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә – вәкаләтле затка) кул куйдыртып тапшыра яки лицензиатка, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә, шулай ук бу хакта лицензиатка элемтә чаралары аша һәм тиешле мәгълүматны ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында https://gji.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән дә хәбәр итә.

Татарстан Республикасы лицензияләү комиссиясенә лицензия бирүдән баш тарту турында тәкъдим әзерләнгән очракта, җаваплы башкаручыга, мондый баш тартуга нигез булган норматив хокукый актларның һәм бүтән төрле документларның конкрет нигезләмәләренә сылтама белән, баш тарту сәбәпләренә дәлилле нигезләүне яки, әгәр баш тарту сәбәбе булып тикшерү барышында лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә туры килмәве ачыклануы торса, лицензия алырга теләүчене тикшерү акты реквизитларын күрсәтергә кирәк. Материалларны карау һәм лицензия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү күрсәтелгән материаллар килгән датадан башлап 10

эш көненнән соңга калмыйча Татарстан Республикасы лицензияләү комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Лицензия бирүдән баш тарту турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы Татарстан Республикасы лицензияләү комиссиясеннән карар алынган көннән башлап 2 эш көне эчендә чыгарыла.

Лицензия бирүдән баш тарту турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгына имза салынган көннән башлап 3 эш көне эчендә җаваплы башкаручы лицензия алырга теләгән затка лицензия бирүдән баш тарту турында хәбәр итә, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә. Баш тарту турында хәбәрдә мондый баш тартуга нигез булган норматив хокукый актларның һәм башка документларның конкрет нигезләмәләренә сылтама белән, баш тарту сәбәпләренә дәлилле нигезләү күрсәтелә. Әгәр баш тарту сәбәбе булып тикшерү барышында лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә туры килмәве ачыклануы торса, тикшерү актының реквизитлары күрсәтелә. Баш тарту турында хәбәр шулай ук лицензия алырга теләүчегә мәгълүмат-коммуникация технологияләре ярдәмендә дә җибәрелергә мөмкин.

Лицензияләү процедурасы тәмамлангач лицензияне тапшыру (алу) көненнән башлап 5 эш көне эчендә җаваплы башкаручы түбәндәге документлардан лицензия эшен формалаштыра:

а) лицензия алырга теләүченең лицензия бирү турында гаризасы, лицензиатның гаризасы һәм тиешле гаризага теркәлә торган документлар;

б) лицензия бирү турында, лицензия бирүдән баш тарту турында, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында, лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату, техник хатаны төзәтү, дубликат бирү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыклары;

в) имзаланган һәм теркәлгән лицензия күчермәсе;

г) лицензия алырга теләгән затка, лицензиатка карата тикшерүләр билгеләү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыклары, тикшерү актларының, лицензия таләпләре бозылуның ачыкланган очракларын бетерү турында күрсәтмәләрнең, административ хокук бозулар турында беркетмәләрнең, административ җәза билгеләү турында карарларның һәм лицензия контролен гамәлгә ашыруга бәйле башка документларның күчермәләре;

д) лицензияне гамәлдән чыгару турында суд карарыннан өземтә;

е) лицензияләүне гамәлгә ашыруга бәйле хәбәрләрнең һәм башка документларның күчермәләре.

Лицензия эше, гариза бирүчегә лицензия бирүгә яки лицензия бирүдән баш тартуга бәйсез рәвештә, мәгълүматның конфиденциальлеген тәэмин итү таләпләрен үтәп, вакыты чикләнмичә ТР Дәүләт торак инспекциясендә сакланырга тиеш.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензия бирү турында боерык, лицензияләр реестрында теркәү, лицензия, лицензия бирүдән баш тарту турында боерык, баш тарту турында хәбәр, лицензия эше.

## Техник хатаны төзәтү

3.8. Лицензиядә техник хата ачыкланган очракта, лицензиат ТР Дәүләт торак инспекциясенә әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра.

Гариза бирүче әлеге Регламентның 5 нче кушымтасындагы форма буенча техник хатаны төзәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

Җаваплы башкаручы документларны карый һәм нигезләре булган очракта лицензиягә төзәтмәләр кертү максатында техник хатаны төзәтү турында боерык проектын әзерли.

Техник хатаны төзәтү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы һәм лицензия бер үк вакытта ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгы тарафыннан имзалана һәм лицензияләр реестрында теркәлә.

Имзаланган һәм теркәлгән лицензия лицензиатка (Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры китереп рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә – вәкаләтле затка) кул куйдыртып тапшырыла яки лицензиатка, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрелә.

Техник хата җибәрелгән лицензия акт нигезендә юкка чыгарыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура лицензиядә язу, басма хатасын, арифметик хатаны төзәтү турында гариза һәм башка документлар килгән датадан башлап 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында боерык, лицензияләр реестрында теркәү, лицензия.

## Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гаризаны, башка документларны карау һәм лицензия бирү турында (үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында) карар кабул итү

3.9. Лицензияле лицензиат яки аның хокуклы варисы лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза һәм документлар (белешмәләр) белән ТР Дәүләт торак инспекциясенә мөрәҗәгать итә (2 нче кушымта).

Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза юридик затны үзгәртеп кору формасында үзгәрткән, аның исемен, урнашкан урыны адресын, юридик зат тарафыннан лицензияләнүче эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру урыннары адресларын, лицензияләнүче эшчәнлек төрләреннән гыйбарәт, башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген үзгәрткән очракларда тапшырыла.

Юридик затны үзгәртеп кору формасында үзгәрткән очракта лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза ТР Дәүләт торак инспекциясенә лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү нигезе барлыкка килгән көннән башлап 15 көн узганчы тапшырыла.

Юридик затларны берләштерү формасында үзгәрткән очракта, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү фәкать берләшүдә катнаша торган һәр юридик затта үзгәртеп корылган юридик затларның хокуклы варисларын дәүләт теркәвенә алу датасына күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия булуы шарты белән генә рөхсәт ителә.

3.10. Гариза бирүчене консультацияләү әлеге Регламентның 3.2 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.11. Гаризаны кабул итү һәм теркәү Администартив регламентның 3.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.12. Җаваплы башкаручы, лицензиат турында лицензия эшендәге белешмәләрне исәпкә алып, тапшырылган белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуына тикшерү уздыра, түбәндәгеләрне билгеләү максатында:

1) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү нигезләре булуын;

2) гаризада тапшырылган белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын һәм аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән ТР Дәүләт торак инспекциясенә алынган белешмәләр белән чагыштыра.

Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү әлеге Регламентның 3.14 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән көннән башлап 5 эш көне узганчы гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын тикшерү акты

3.13. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү.

Лицензиат тапшырган белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын тикшерүне тәмамлаган датадан башлап 2 эш көне эчендә җаваплы башкаручы лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында (лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында) боерык проектын әзерли.

Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү өчен боерык проекты, гариза һәм документлар ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгы тарафыннан – 2 эш көне эчендә, ләкин лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында яки, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар кабул итү максатында, лицензиаттан килгән лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза теркәлгән датадан башлап 9 эш көне узганчы карала.

Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы һәм лицензия бер үк вакытта ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгы тарафыннан имзалана һәм лицензияләр реестрында теркәлә.

Алмашка үзгәртеп рәсмиләштерегән лицензия бирелә торган лицензия акт буенча юкка чыгарыла.

Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы проекты әзерләнгән очракта, җаваплы башкаручыга мондый баш тартуга нигез булган норматив хокукый актларның һәм башка документларның конкрет нигезләмәләренә сылтама ясап, баш тарту сәбәпләренә дәлилле нигезләү күрсәтергә кирәк.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында боерык, лицензияләр реестрында теркәү, лицензия, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында боерык, баш тарту турында хәбәр.

## ТР Дәүләт торак инспекциясенең башка федераль дәүләт хакимияте органнары, ТР лицензияләү комиссиясе һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнар белән үзара хезмәттәшлек итүе, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган әлеге органнарга җибәрү

3.14. Дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында түбәндәгеләр белән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек гамәлгә ашырыла:

1) Россия Казначылыгы - дәүләт пошлинасын түләү турында белешмәләр алу өчен;

2) Россия Федераль салым хезмәте – Юридик затларның бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләрне һәм Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләрне алу өчен;

3) Россия Эчке эшләр министрлыгы – икътисад өлкәсендәге җинаятьләр өчен, уртача авырлыктагы, авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен алынмаган яисә үтәлмәгән суд хөкеме булуы (булмавы) турында белешмәләр алу өчен;

4) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы – лицензия алырга теләүченең вазыйфаи заты турында лицензиясе гамәлдән чыгарылган лицензиатның бер кулдагы башкарма органы функцияләрен башкаручы затлар, шулай ук лицензиатның уставында яки бүтән документларында күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә карата таләпләр үтәлеше өчен җаваплылык йөкләнгән һәм үзләренә карата квалификациясеннән мәхрүм итү кебек административ җәза кулланылган затлар, лицензиясе гамәлдән чыгарылган һәм (яки) үзләренә карата квалификациясеннән мәхрүм итү кебек административ җәза кулланылган шәхси эшкуарлар реестрында мәгълүматның булуы (булмавы) турында, шулай ук лицензияләрнең җыелма федераль реестрында лицензия алырга теләүчегә элегрәк бирелгән лицензияне гамәлдән чыгару турында мәгълүматларның булмавы турында белешмәләр алу өчен.

Җаваплы башкаручы ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза ТР Дәүләт торак инспекциясенә карау өчен кабул ителгән көннән соңгы көннән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.14.1. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (белешмәләрне) бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура законнарда билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт пошлинасын түләү турында белешмәләр, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрындагы (Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрындагы) белешмәләр, икътисад өлкәсендә җинаятьләр, уртача авырлыктагы җинаятьләр, авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өлкәсендә алынмаган яки үтәлмәгән суд хөкеменең булуы (булмавы) турында белешмәләр, лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи

заты турында лицензиясе гамәлдән чыгарылган лицензиатның бер кулдагы башкарма органы функцияләрен башкаручы затлар, шулай ук лицензиатның уставында яки башка документларында күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә карата таләпләр үтәлеше өчен җаваплылык йөкләнгән һәм үзләренә карата квалификациясеннән мәхрүм итү кебек административ җәза кулланылган затлар, лицензиясе гамәлдән чыгарылган һәм (яки) үзләренә карата квалификациясеннән мәхрүм итү кебек административ җәза кулланылган шәхси эшкуарлар реестрында мәгълүматның булуы (булмавы) турында, шулай ук лицензияләрнең җыелма федераль реестрында лицензия алырга теләүче затка элегрәк бирелгән лицензияне гамәлдән чыгару турында мәгълүматларның булмавы турында белешмәләр яки ТР Дәүләт торак инспекциясенә белешмәләрнең булмавы турында юлланган хәбәр.

Лицензия дубликаты бирү

3.15. Лицензияне югалткан яки аны бозган очракта, гариза бирүче лицензия дубликаты бирү турында гариза (4 нче кушымта) белән ТР Дәүләт торак инспекциясенә мөрәҗәгать итә.

3.16. Гариза бирүчене консультацияләү әлеге Регламентның 3.2 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.17. Гаризаны кабул итү һәм теркәү әлеге Регламентның 3.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.18. Җаваплы башкаручы, лицензиат турында лицензия эшендәге белешмәләрне исәпкә алып, тапшырылган белешмәләрнең дөрес булуына тикшерү уздыра, түбәндәгеләрне билгеләү максатында:

лицензия дубликаты бирү өчен нигезләр булуын;

гаризада тапшырылган белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын һәм аларны ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән Россия Казначылыганнан алына торган белешмәләр (лицензия дубликаты бирү өчен дәүләт пошлинасын түләү турында белешмәләр) белән чагыштыра.

Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү әлеге Регламентның 3.14 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар лицензия дубликаты бирү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры китереп, башка документлар (белешмәләр) тулы күләмендә ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән көннән башлап 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын тикшерү акты.

3.19. Лицензия дубликаты бирү өчен боерык проекты, гариза һәм документлар лицензиаттан килгән лицензия дубликаты бирү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза теркәлгән датадан башлап 3 эш көне эчендә, лицензия дубликаты бирү турында карар кабул итү максатында, ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгы тарафыннан карала.

Лицензия дубликаты бирү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы һәм «дубликат» һәм «лицензиянең төп нөсхәсе гамәлдә түгел дип танылa» тамгалары белән лицензия бланкында лицензия дубликаты бер үк вакытта ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгы тарафыннан имзалана һәм лицензияләр реестрында теркәлә.

3.19.1. Җаваплы башкаручы лицензиатка лицензия дубликатын тапшыра яки, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензия дубликаты бирү турында боерык, лицензия дубликаты, лицензияләр реестрында теркәү.

Лицензияләр реестрыннан конкрет лицензия турында белешмәләр бирү турындагы гаризаны карау

3.20. Лицензияләр реестрында булган конкрет лицензиатлар турында язма өземтәләр, Татарстан Республикасы лицензияләү комиссиясе тарафыннан кабул ителгән карарлар турында актларның күчермәләре, сорала торган белешмәләрнең булмавы турында белешмәләр рәвешендәге мәгълүматлар физик затларга һәм юридик затларга аларның гаризалары нигезендә түләүсез нигездә бирелә.

3.20.1. Гариза бирүчене консультацияләү әлеге Регламентның 3.2 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Бүлек белгече лицензияләр реестрында булган мәгълүматны бирү турында рәсми мөрәҗәгать ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән көннән башлап лицензияләр реестрыннан өземтә, Татарстан Республикасы лицензияләү комиссиясе кабул иткән карарлар турында акт күчермәсен яки сорала торган белешмәләрнең булмавы турында белешмә әзерли.

Бүлек белгече гариза бирүчегә соралган мәгълүматны тапшыра яки, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп гариза бирүче адресына яки мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар тиешле гариза килгән көннән соң 5 эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияләр реестрыннан өземтә, Татарстан Республикасы лицензияләү комиссиясе кабул иткән карарлар турында акт күчермәсе, соралган белешмәләрнең булмавы турында белешмә.

Лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату

3.21. «Лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату» административ процедурасы түбәндәгеләргә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла:

а) лицензиат тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген туктату турында гариза тапшырылуы аркасында;

б) юридик затның эшчәнлеген туктатуы турында (үзгәртеп корылу яки берләшү формасында үзгәртелү очракларыннан тыш, үзгәртелгән юридик затларның хокуклы варисын дәүләт теркәвенә алу датасына берләшүдә катнаша торган һәр юридик затта бер үк эшчәнлек төренә лицензия булганда) яки физик

зат тарафыннан шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлек туктатылуы турында юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органыннан мәгълүмат килүгә бәйле рәвештә;

в) ТР Дәүләт торак инспекциясенә лицензияне гамәлдән чыгару турында законлы көченә кергән суд карарыннан өземтә килүе.

3.21.1. Гариза бирүчене консультацияләү Административ регламентның 3.2 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.22. Җаваплы башкаручы күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген туктату турында тиешенчә рәсмиләштергән гариза; юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органыннан тиешле реестрга юрдик затның эшчәнлеген туктатуы турында яки физик затның шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлеген туктатуы турында язу кертелү датасы турында мәгълүмат; лицензияне гамәлдән чыгару турында законлы көченә кергән суд карары (лицензияне гамәлдән чыгару турында законлы көченә кергән суд карарыннан өземтә) ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән көннән башлап 10 эш көне эчендә:

а) лицензия эшендә лицензиат турында булган белешмәләрне исәпкә алып, тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген тикшерә;

б) күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату турында боерык проекты рәсмиләштерә;

в) лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату турындагы белешмәләрне лицензияләр реестрына кертә;

г) лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату турында, ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы күчермәсен теркәп, лицензиатка хәбәр итә яки, кулга тапшыру турында билгеләп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә.

Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү әлеге Регламентның 3.14 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген туктату турында гариза, лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату турындагы боерык һәм гариза бирүчегә лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату турындагы хәбәр күчермәсе лицензия эшенә теркәлә.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату турында боерык, лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату турында хәбәр, лицензияләр реестрында теркәү.

### Лицензиянең гамәлдә булу вакытын озынайту турындагы гаризаны карау

3.23. Лицензиат лицензиянең гамәлдә булу вакытын озынайту турында гариза белән ТР Дәүләт торак инспекциясенә мөрәҗәгать итә.

Лицензиянең гамәлдә булу вакытын озынайту турында гариза лицензиянең гамәлдә булу вакыты чыккан көнгә кадәр 60 эш көне алдан һәм гамәлдә булу

вакыты чыккач 45 эш көне узганчы ТР Дәүләт торак инспекциясенә тапшырыла.

3.24. Гариза бирүчене консультацияләү әлеге Регламентның 3.2 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.25. Гаризаны кабул итү, теркәү әлеге Регламентның 3.3 пункты нигезендә башкарыла.

3.26. Җаваплы башкаручы түбәндәгеләрне тикшерә:

а) лицензиянең гамәлдә булу вакытын озынайту турында гариза бирү вакытының үтәлешен;

б) лицензиатның Россия Федерациясе Торак кодексының 193 статьясындагы 1 өлешендәге 1-6.1 пунктларында каралган лицензия таләпләренә туры килүен;

в) Россия Федерациясе Торак кодексының 161 статьясындагы 2.3 өлешендә каралган таләпләр үтәлешен;

г) Россия Федерациясе Торак кодексының 162 статьясындагы 2 өлешендә каралган күпфатирлы йорт белән идарә итү килешүе буенча бурычлар үтәлешен;

д) Россия Федерациясе Торак кодексының 45 статьясындагы 3.1 өлешендә каралган таләпләр үтәлешен;

е) Россия Федерациясе Торак кодексының 162 статьясындагы 7 өлешендә һәм 198 статьясының 6 өлешендә каралган таләпләр үтәлешен;

ж) лицензиатның түбәндәге лицензия таләпләрен тупас бозмавын:

- РФ Торак кодексының 161 статьясының 2.3 өлешендә каралган лицензия таләбен бозу, нәтиҗәдә гражданнарның гомеренә зыян яки сәламәтлегенә каты зыян китерү, моның законлы көченә кергән суд карары белән расланган булуы;

- күпфатирлы йортларда җылылык белән тәэмин итү (җылыту, кайнар су белән тәэмин итү) системаларын тиешенчә карап тоту максатларында башкарыла торган җылылык кертү төеннәренә һәм системаларына ныклылык һәм тыгызлык буенча сынаулар (гидравлик сынаулар), җылыту системаларын юдырту һәм җайга салу эшләрен уздырмау өлешендә лицензиат тарафыннан РФ Торак кодексының 161 статьясының 2.3 өлешендә каралган лицензия таләбенең бозылуы;

- күпфатирлы йорт белән идарә итү килешүен үти башлаган көннән алып 30 календарь көне эчендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Йорт һәм фатир эчендәге газ җиһазларыннан файдаланганда һәм аларны карап тотканда куркынычсызлык тәэмин итү чаралары турында» 2013 елның 14 маендагы 410 номерлы карары белән расланган Газ белән тәэмин итү коммуналь хезмәтен күрсәткәндә йорт һәм фатир эчендәге газ җиһазларыннан файдаланганда һәм аларны карап тотканда куркынычсызлык тәэмин итү өлешендә газдан файдалану кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләр нигезендә йорт эчендәге газ җиһазы системаларын тиешенчә карап тоту максатларында эшләр башкару турында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Лифтлардан, инвалидларны күтәртә торган платформалардан, пассажир конвейерларыннан (хәрәкәтле җәяүле юлларыннан), эскалаторлардан, метрополитеннардагы эскалаторлардан тыш, куркынычсыз файдалануны һәм аларны карап тотуны оештыру турында» 2017 елның 24 июнендәге 743 номерлы карары белән расланган Лифтлардан,

инвалидларны күтәртә торган платформалардан, пассажир конвейерларыннан (хәрәкәтле җәяүле юлларыннан), эскалаторлардан, метрополитеннардагы эскалаторлардан тыш, куркынычсыз файдалануны һәм аларны карап тотуны оештыру кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләр нигезендә лифтларны, инвалидларны күтәртә торган платформаларны эксплуатацияләү, шул исәптән аларга техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау буенча эшләр башкару турында килешү төземәү өлешендә РФ Торак кодексының 161 статьясының 2.3 өлешендә каралган лицензия таләбенең бозылуы, лифтлардан, инвалидларны күтәртү платформаларыннан файдалану, шул исәптән аларга хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау буенча эшләрне идарәче оешмалар тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Лифтлардан, инвалидларны күтәртә торган платформалардан, пассажир конвейерларыннан (хәрәкәтле җәяүле юлларыннан), эскалаторлардан, метрополитеннардагы эскалаторлардан тыш, куркынычсыз файдалануны һәм аларны карап тотуны оештыру турында» 2017 елның 24 июнендәге 743 номерлы карары белән расланган Лифтлардан, инвалидларны күтәртә торган платформалардан, пассажир конвейерларыннан (хәрәкәтле җәяүле юлларыннан), эскалаторлардан, метрополитеннардагы эскалаторлардан тыш, куркынычсыз файдалануны һәм аларны карап тотуны оештыру кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләр нигезендә мөстәкыйль башкарылган очрактан тыш;

- күпфатирлы йорт белән идарә итү килешүен үти башлаган көннән башлап 30 календарь көне эчендә күпфатирлы йортта уртак мөлкәттән файдаланганда һәм аны карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурсларны сатып алу максатларында ресурс белән тәэмин итүче оешмалар белән килешүләр төзелмәве өлешендә лицензиат тарафыннан РФ Торак кодексының 162 статьясының 2 өлешендә каралган лицензия таләбе бозылу;

- лицензиатның күпфатирлы йортта милекчеләргә һәм торак урыннардан файдаланучыларга тиешле төрдәге коммуналь хезмәт күрсәтүне һәм (яки) күпфатирлы йортта уртак мөлкәттән файдаланганда һәм аны карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурсларны сатып алуны тәэмин итү максатларында ресурс белән тәэмин итү буенча төзелгән килешү нигезендә йөкләмәләрнең уртача 2 айлык зурлыгына тигез яки аны арттырып җибәрә торган күләмдә ресурс белән тәэмин итүче оешма каршысында законлы көченә кергән суд актында танылган яки расланган түләячәк әҗәте булу өлешендә РФ Торак кодексының 162 статьясының 2 өлешендә каралган лицензия таләбенең бозылуы, әлеге әҗәтне алга таба лицензиат тарафыннан түләү фактына бәйсез рәвештә;

- Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда күпфатирлы йортка һәм мондый күпфатирлы йорт белән идарә итүгә бәйле техник документларны, күпфатирлы йортта уртак мөлкәт составына керә торган урыннардан ачкычларны, күпфатирлы йортта уртак мөлкәт составына керә торган җайланмалардан һәм күпфатирлы йорттан файдалану һәм аның белән идарә итү өчен кирәкле башка техник чаралардан һәм җайланмалардан файдалану өчен электрон кодларны (алга таба – күпфатирлы йортка бәйле техник документлар һәм әлеге күпфатирлы йорт белән идарә итүгә бәйле башка документлар, техник чаралар һәм җайланма) күпфатирлы йорт белән идарә итү

йөкләмәсен үз өстенә алган идарәче оешмага, торак милекчеләре ширкәтенә, торак кооперативына, торак-төзелеш кооперативына, ә күпфатирлы йорт белән идарә итү турыдан-туры мондый йорттагы биналарның милекчеләре тарафыннан гамәлгә ашырылган очракта, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында биналарның милекчеләренең гомуми җыелышы карарында күрсәтелгән милекчеләрнең берсенә яки, мондый милекче күрсәтелмәгән булса, әлеге йорттагы теләсә кайсы бина милекчесенә тапшырудан баш тарту яки күпфатирлы йортка бәйле техник документларны һәм әлеге күпфатирлы йорт белән идарә итүгә бәйле башка документларны, техник чараларны һәм җайланманы тапшырудан читләшү өлешендә РФ Торак кодексының 162 статьясының 2 өлешендә каралган лицензия таләпләренең бозылуы яисә күпфатирлы йортка бәйле техник документларны һәм әлеге күпфатирлы йорт белән идарә итүгә бәйле башка документларны, техник чараларны һәм җайланманы тапшыруның федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган тәртибе һәм ваытлары бозылу;

- Россия Федерациясе субъектының лицензияләр реестрыннан мондый йорт турында белешмәләр төшереп калдырылган көннән башлап 3 көн эчендә лицензиат тарафыннан күпфатирлы йорт белән идарә итү эшчәнлеген туктатмау өлешендә РФ Торак кодексының 162 статьясының 7 өлешендә һәм РФ Торак кодексының 198 статьясының 6 өлешендә каралган лицензия таләбенең бозылуы, мондый эшчәнлекне РФ Торак кодексының 200 статьясының 3 өлеше нигезләмәләре нигезендә гамәлгә ашырудан тыш;

- лицензиат тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2013 елның 15 маендагы 416 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенең 13 пунктында каралган авария-диспетчерлык хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыруга бәйле таләпләрнең бозылуы өлешендә РФ Торак кодексының 162 статьясының 7 өлешендә һәм 198 статьясының 6 өлешендә каралган лицензия таләбе бозылу.

Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү әлеге Регламентның 3.14 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.27. Лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында карар кабул итү өчен билгеләнгән процедуралар тиешле гариза кергән көннән соң 30 календарь көне узганчы гамәлгә ашырыла.

3.28. Тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы лицензиянең гамәлдә булу срогын озынайту турында (яки лицензиянең гамәлдә булу срогын озынайтудан баш тарту турында) боерык проекты рәсмиләштерә.

3.29. Җаваплы башкаручы лицензиянең гамәлдә булу вакытын озынайту (яки лицензиянең гамәлдә булу вакытын озынайтудан баш тарту) турындагы боерыкны лицензиатка тапшыра яки, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булу вакытын озынайту (яки лицензиянең гамәлдә булу вакытын озынайтудан баш тарту) турындагы боерык.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуын тикшереп тору түбәндәгеләрдән гыйбарәт: гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, шикаятьләрне карау, тикшерүләр уздыру, гариза бирүче-ләрнең мөрәҗәгатьләре буенча карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләү, ТР Дәүләт торак инспекциясенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылма-вына) карарлар әзерләү.

Административ процедуралар үтәлешен контрольдә тоту формалары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- хезмәт күрсәтү буенча документларның проектларына экспертиза уздыру. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларга имза салу тора;
- билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү;
- Бүлектә эш башкаруны билгеләнгән тәртиптә тикшерү.

Тикшерүләр планлы (ТР Дәүләт торак инспекциясенең еллык эш планы нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы тикшерүләр уздырылганда хезмәт күрсәтүгә бәйле (комплекслы тикшерүләр) яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча мәсьәләләр каралырга мөмкин.

4.2. Хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контрольлек ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары тарафыннан башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә һәм карарлар кабул ителгәндә гамәлләр кылуны тикшереп тору максатларында ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасарына хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырылырга мөмкин.

Административ процедураларның сроклары, эзлеклелеге һәм эчтәлеге бозылу очраклары һәм сәбәпләре турында белгеч кичекмәстән дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган җитәкчесенә хәбәр итә, шулай ук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрә.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ТР Дәүләт торак инспекциясе эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

4.5. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә дәүләт хезмәтеннән файдаланганда гражданнарның хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр ТР Дәүләт торак инспекциясе, ТР Дәүләт торак инспекциясе вазыйфаи заты, граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгына шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сәбәпле ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгы кабул иткән карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

5.2. Гариза бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче оргaндагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында туктатып тору нигезләре каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтыннан (https://gji.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм (http://www.gosuslugi.ru/) порталыннан җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның гариза бирүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтүләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләре.

Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача яисә, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта

гариза бирүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, ТР Дәүләт торак инспекциясендә гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба гариза бирүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Форма Россия Төзелеш министрлыгының 28.10.2014 ел, № 657/пр боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенә

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча (лицензия бирү артыннан беренче мәртәбә мөрәҗәгать иткәндә) эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия бирү турында
ГАРИЗА

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия бирүегез турында үтенәм

______________________________________________________________
(лицензия алырга теләгән затның тулы һәм (булган очракта) кыска атамасын (шул исәптән фирма исемен) күрсәтергә)

Лицензия алырга теләүче затның оешу-хокук формасы ____________________

Лицензия алырга теләүче затның урнашкан урыны ________________________

______________________________________________________________
(лицензия алырга теләүченең урнашкан адресы күрсәтелә)

Юридик затның төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) _______________________

Юридик зат турында мәгълүматларны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына яки шәхси эшкуар турындагы мәгълүматларны Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына кертү фактын раслый торган документ белешмәләре

______________________________________________________________
(Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында һәм Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында язу кәгазенең реквизитлары, дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашырган органның урнашкан адресын күрсәтеп (уставка үзгәрешләр кертелгән очракта, дәүләт теркәвенә алган органның урнашкан адресын күрсәтеп, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына һәм Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына кертелгән барлык тиешле язу кәгазенең реквизитлары күрсәтелә))

Салым түләүче затның тәңгәллек номеры ______________________________

Лицензия алырга теләгән затны салым органында исәпкә кую турында документ белешмәләре ____________________________________________

______________________________________________________________
(лицензия алырга теләгән затны салым органында исәпкә кую сәбәбенең коды һәм датасы, лицензия алырга теләүче затны салым исәбенә кую турында таныклык реквизитлары)

Лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының квалификация аттестаты

______________________________________________________________
(квалификация аттестатының номеры, кем тарафыннан бирелгән, бирелү датасы)

Мәгълүмат ачуга карата Россия Федерациясе Торак кодексының 161

статьясының 10.1 өлешендә билгеләнгән таләпләр нигезендә лицензия алырга теләгән зат үз эшчәнлеге турында мәгълүмат ача торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яки) рәсми массакүләм мәгълүмат чаралары турында белешмәләр

______________________________________________________________________________

(лицензия алырга теләгән зат лицензия бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән датага күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырган очракта тапшырыла)

Раслыйм:

- лицензия алырга теләүченең вазыйфаи затында икътисад өлкәсендәге җинаятьләр өчен, уртача авырлыктагы, авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен алынмаган яисә үтәлмәгән суд хөкеме юк;

- лицензиатның лицензиясе гамәлдән чыгарылган бер кулдагы башкарма орган функцияләрен гамәлгә ашыручы затлар, шулай ук лицензиат уставында яисә башка документларында күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәү өчен җаваплылык йөкләнгән һәм үзләренә карата квалификациясен алу рәвешендә административ җәза кулланылган затлар, лицензиясе гамәлдән чыгарылган һәм квалификациясен алу рәвешендә административ җәза билгеләнгән шәхси эшкуарлар реестрында лицензия алырга теләүченең вазыйфаи заты турында мәгълүмат юк;

- лицензияләрнең җыелма федераль реестрында лицензия алырга теләүчегә элегрәк бирелгән лицензияне гамәлдән чыгару турында мәгълүмат юк.

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия биргән өчен лицензия алырга теләүче тарафыннан дәүләт пошлинасы түләнгәнлеген раслаучы документ реквизитлары

______________________________________________________________________________

Лицензия алырга теләгән затның телефон (факс) номеры ___________________

Лицензия алырга теләгән затның электрон почта адресы ___________________

Лицензияләү процедурасы турында хәбәрне электрон формада җибәрүегез турында үтенәм: ______________________________________________________

(әйе/юк)

Мин, ____________________________________________________________________,

(лицензия алырга теләүченең вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, атасының исеме - тулысынча)

«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге федераль законның 9 статьясы нигезендә минем персональ белешмәләремне автоматлаштырылган рәвештә, шулай ук автоматлаштырылган чаралардан файдаланмыйча гына, эшкәртүгә, ә атап әйткәндә «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге федераль законның 3 статьясының беренче өлешендәге 3 пунктында каралган гамәлләргә, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 193 статьясының 1 өлешендәге 3, 4 пунктларда билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килүне тикшерү максатларында минем персональ белешмәләремне эшкәртүгә, тапшыруга һәм файдалануга ризалык бирәм.

Тутыру датасы __ __________ 20__ ел.

| ______________________ | ______________________ | ______________________ |
|---|---|---|
| (лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының вазыйфа атамасы) | (лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының имзасы) | (лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта)) |

Мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Форма Россия Төзелеш министрлыгының 28.10.2014 ел, № 657/пр боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенә

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга (юридик затны бүлү яки аның составыннан бер яки берничә юридик затны аерып чыгару формасында үзгәртеп коруга бәйле рәвештә) лицензия бирү турында

ГАРИЗА

Юридик затны аның составыннан бер яки берничә юридик затны бүлеп чыгару формасында (кирәклесен күрсәтергә) үзгәртеп коруга бәйле рәвештә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия бирүегез турында үтенәм

_______________________________________________________________________

(лицензия алырга теләгән затның тулы һәм (булган очракта) кыска атамасын (шул исәптән фирма исемен) күрсәтергә)

Лицензия алырга теләгән затның оешу-хокук формасы____________________

Лицензия алырга теләгән затның урнашу урыны _________________________

_______________________________________________________________________

(лицензия алырга теләүченең урнашкан адресы күрсәтелә)

Юридик затның төп дәүләт теркәвенә алу номеры (ОГРН)__________________

_______________________________________________________________________

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына юридик зат турында белешмәләр кертелү фактын раслый торган документ белешмәләре ____________________

_______________________________________________________________________

(дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашырган органның урнашкан урыны адресын күрсәтеп, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелгән язу кәгазенең реквизитлары (уставка үзгәрешләр кертелгән очракта, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелгән барлык тиешле язу кәгазенең реквизитлары күрсәтелә, дәүләт теркәвенә алган органның урнашкан урыны адресын күрсәтеп))

Салым түләүче затның тәңгәллек номеры_________________________

Лицензия алырга теләүче затны салым органында исәпкә кую турында документ белешмәләре ______________________________________________

_______________________________________________________________________

(лицензия алырга теләгән затны салым органында исәпкә кую сәбәбенең коды һәм датасы, лицензия алырга теләүче затны салым исәбенә кую турында таныклык реквизитлары)

Лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының квалификация аттестаты

_______________________________________________________________________

(квалификация аттестатының номеры, кем тарафыннан бирелгән, бирелү датасы)

Мәгълүмат ачуга карата Россия Федерациясе Торак кодексының 161 статьясының 10.1 өлешендә билгеләнгән таләпләр нигезендә лицензия алырга

теләгән зат үз эшчәнлеге турында мәгълүмат ача торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яки) рәсми массакүләм мәгълүмат чаралары турында белешмәләр________________________________
______________________________________________________________________
(лицензия алырга теләүче зат лицензия бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән датага күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырган очракта тапшырыла)

Раслыйм:

- лицензия алырга теләүченең вазыйфаи затында икътисад өлкәсендәге җинаятьләр өчен, уртача авырлыктагы, авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен алынмаган яисә үтәлмәгән суд хөкеме юк;

- лицензиатның лицензиясе гамәлдән чыгарылган бер кулдагы башкарма орган функцияләрен гамәлгә ашыручы затлар, шулай ук лицензиат уставында яисә башка документларында күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәү өчен җаваплылык йөкләнгән һәм үзләренә карата квалификациясен алу рәвешендә административ җәза кулланылган затлар, лицензиясе гамәлдән чыккан һәм квалификациясен алу рәвешендә административ җәза билгеләнгән шәхси эшкуарлар реестрында лицензия алырга теләүче затның вазыйфаи заты турында мәгълүмат юк;

- лицензияләрнең җыелма федераль реестрында лицензия алырга теләүчегә элегрәк бирелгән лицензияне гамәлдән чыгару турында мәгълүмат юк.

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия биргән өчен лицензия алырга теләүче зат тарафыннан дәүләт пошлинасы түләнгәнлеген раслый торган документ реквизитлары ___________
______________________________________________________________________

Лицензия алырга теләүче затның телефон (факс) номеры __________________

Лицензия алырга теләгән затның электрон почта адресы __________________

Лицензияләү процедурасы турында хәбәрне электрон формада җибәрүегез турында үтенәм: ______________________________________________________
(әйе/юк)

Мин,__________________________________________________________________
(лицензия алырга теләүченең вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, атасының исеме - тулысынча)

«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге федераль законның 9 статьясы нигезендә минем персональ белешмәләремне автоматлаштырылган рәвештә, шулай ук автоматлаштырылган чаралардан файдаланмыйча гына, эшкәртүгә, ә атап әйткәндә «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге федераль законның 3 статьясының беренче өлешендәге 3 пунктында каралган гамәлләргә, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 193 статьясының 1 өлешендәге 3, 4 пунктларда билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килүне тикшерү максатларында минем персональ белешмәләремне эшкәртүгә, тапшыруга һәм файдалануга ризалык бирәм.

Тутыру датасы __ __________ 20__ ел.

| | | |
|---|---|---|
| ___________________ | ___________________ | ___________________ |
| (лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының вазыйфа атамасы) | (лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының имзасы) | (лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта)) |

Мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Форма Россия Төзелеш
министрлыгының 28.10.2014 ел, №
657/пр боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенә

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында

ГАРИЗА

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияне яңадан рәсмиләштерүегез турында үтенәм

___________________________________________________________________

(күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия реквизитлары күрсәтелә) <*>

бирелдe ___________________________________________________________,

(лицензияләүче орган атамасы)

сәбәбе: ___________________________________________________________

(күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү нигезе күрсәтелә)

Лицензиатның тулы һәм (булган очракта) кыска атамасы (шул исәптән фирма исеме) ___________________________________________________

Лицензиатның оешу-хокук формасы_______________________________

Лицензиатның урнашкан урыны _________________________________

(лицензиатның урнашкан адресы күрсәтелә)

Юридик затның төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) ___________________

Юридик зат турында мәгълүматларны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына яки шәхси эшкуар турындагы мәгълүматларны Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына кертү фактын раслый торган документ белешмәләре

___________________________________________________________________

(Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында һәм Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында язу кәгазенең реквизитлары, дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашырган органның урнашкан адресын күрсәтеп (уставка үзгәрешләр кертелгән очракта, дәүләт теркәвенә алган органның урнашкан адресын күрсәтеп, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына һәм Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына кертелгән барлык тиешле язу кәгазенең реквизитлары күрсәтелә))

Салым түләүченең тәңгәллек номеры ____________________________

Лицензиатны салым органында исәпкә кую турында документ белешмәләре
______________________________________________________________

(лицензиатны салым органында исәпкә кую сәбәбенең коды һәм датасы, лицензиатны салым исәбенә кую турында таныклык реквизитлары)

Лицензиатның вазыйфаи затының квалификация аттестаты ________________
______________________________________________________________

(квалификация аттестатының номеры, кем тарафыннан бирелгән, бирелү датасы)

Мәгълүмат ачуга карата Россия Федерациясе Торак кодексының 161 статьясының 10.1 өлешендә билгеләнгән таләпләр нигезендә лицензия алырга теләгән зат үз эшчәнлеге турында мәгълүмат ача торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яки) рәсми массакүләм мәгълүмат чаралары турында белешмәләр_______________________________
______________________________________________________________

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштергән өчен лицензиат тарафыннан дәүләт пошлинасы түләнгәнлеген раслый торган документ реквизитлары
______________________________________________________________

Лицензиатның телефон (факс) номеры_________________________________

Лицензиатның электрон почта адресы__________________________________

Лицензияләү процедурасы турында хәбәрне электрон формада җибәрүегез турында үтенәм: _____________________________________________________

(әйе/юк)

Мин, ____________________________________________________________,

(лицензиатның вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, атасының исеме) «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге федераль законның 9 статьясы нигезендә минем персональ белешмәләремне автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштырылган чаралардан файдаланмыйча эшкәртүгә, ә атап әйткәндә «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге федераль законның 3 статьясының беренче өлешендәге 3 пунктында каралган гамәлләргә, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 193 статьясының 1 өлешендәге 3, 4 пунктларда билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килүне тикшерү максатларында минем персональ белешмәләремне эшкәртүгә, тапшыруга һәм файдалануга ризалык бирәм.

Тутыру датасы __ __________ 20__ ел.

| _____________________ | ___________________ | ______________________ |
|---|---|---|
| (лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының вазыйфа атамасы) | (лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының имзасы) | (лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта)) |

Мөһер урыны (булган очракта)

--------------------------------------------------------------------------------------------------------------

<*> Берләшү, кушу, үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртелгән очракта үзгәртелә торган барлык юридик затларның күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләре реквизитлары күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

(форма Россия Төзелеш министрлыгының 2014 елның 28 октябрендәге 657/пр номерлы боерыгы белән расланган)

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенә

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия дубликатын бирү турында

ГАРИЗА

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия дубликаты бирүегез турында үтенәм ______________________
________________________________________________________________________

(күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия реквизитлары күрсәтелә)

бирелде ______________________________________________________________,

(лицензияләүче орган атамасы)

сәбәбе_______________________________________________________________

(күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия дубликатын бирү нигезе күрсәтелә)

Лицензиатның тулы һәм (булган очракта) кыска атамасы (шул исәптән фирма исеме) ________________________________________________________________

Организационно-правовая форма лицензиата _______________________________

Лицензиатның урнашкан урыны __________________________________________

(лицензиатның урнашкан адресы күрсәтелә)

Юридик затның төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) ________________________

Юридик зат турында мәгълүматларны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына яки шәхси эшкуар турындагы мәгълүматларны Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына кертү фактын раслый торган документ белешмәләре

________________________________________________________________________

(Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында һәм Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында язу кәгазенең реквизитлары, дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашырган органның урнашкан адресын күрсәтеп (уставка үзгәрешләр кертелгән очракта, дәүләт теркәвенә алган органның урнашкан адресын күрсәтеп, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына һәм Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына кертелгән барлык тиешле язу кәгазенең реквизитлары күрсәтелә))

Салым түләүче затның тәңгәллек номеры ________________________________

Лицензиатны салым органында исәпкә кую турында документ белешмәләре
______________________________________________________________________
(лицензиатны салым органында исәпкә кую сәбәбенең коды һәм датасы, лицензиатны салым исәбенә кую турында таныклык реквизитлары)

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия дубликаты бирү өчен лицензиат тарафыннан дәүләт пошлинасы түләнгәнлеген раслый торган документ реквизитлары
______________________________________________________________________

Лицензиатның телефон (факс) номеры __________________________________

Адрес электронной почты лицензиата __________________________________

Лицензияләү процедурасы турында хәбәрне электрон формада җибәрүегез турында үтенәм:____________________________________________________
(әйе/юк)

Тутыру датасы __ __________ 20__ ел.

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ (лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының вазыйфа атамасы) | ____________________ (лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының имзасы) | ____________________ (лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта)) |

Мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенең
күпфатирлы йортлар белән
идарә итү буенча эшкуарлык
эшчәнлеген лицензияләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
5 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенә

Техник хата төзәтү турында
ГАРИЗА

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиядә техник хатаны төзәтүегез турында үтенәм________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________,
(күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия реквизитлары күрсәтелә)

бирелде ____________________________________________________________
(лицензияләүче орган атамасы)

сәбәбе: ____________________________________________________________
(күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиядә техник хатаны төзәтү нигезе күрсәтелә)

Лицензиатның тулы һәм (булган очракта) кыска атамасы (шул исәптән фирма исеме) ______________________________________________________________

Лицензиатның оешу-хокук формасы ______________________________

Лицензиатның урнашкан урыны _________________________________
(лицензиатның урнашкан адресы күрсәтелә)

Юридик затның төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН)____________________
____________________________________________________________________

Юридик зат турында мәгълүматларны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына яки шәхси эшкуар турындагы мәгълүматларны Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына кертү фактын раслый торган документ белешмәләре

____________________________________________________________________
(Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында һәм Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында язу кәгазенең реквизитлары, дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашырган органның урнашкан адресын күрсәтеп (уставка үзгәрешләр кертелгән очракта, дәүләт теркәвенә алган органның урнашкан адресын күрсәтеп, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына һәм Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына кертелгән барлык тиешле язу кәгазенең реквизитлары күрсәтелә))

Салым түләүченең тәңгәллек номеры ______________________________

Лицензиатны салым органында исәпкә кую турында документ белешмәләре

____________________________________________________________________
(лицензиатны салым органында исәпкә кую сәбәбенең коды һәм датасы, лицензиатны салым исәбенә кую турында таныклык реквизитлары)

Лицензиатның телефон (факс) номеры _____________________________

Лицензаитның электрон почта адресы ____________________________________
Лицензияләү процедурасы турында хәбәрне электрон формада җибәрүегез турында үтенәм:________________________________________________________
(әйе/юк)

Кушымта:

1. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен лицензиянең төп нөсхәсе;
2. Лицензиягә белешмәләр кертүгә нигез булган документларның төп нөсхәләре.

Тутыру датасы «__» _________ 20__ ел

| ______________________ | ______________________ | ______________________ |
|---|---|---|
| (лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының вазыйфа атамасы) | (лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының имзасы) | (лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта)) |

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

(бертип форма РФ Хөкүмәтенең 2011 елның 6 октябрендәге 826 номерлы карары белән расланган)

ЛИЦЕНЗИЯНЕҢ БЕРТИП ФОРМАСЫ<*>

(алгы бите)

Россия Федерациясе Дәүләт гербы сурәте

___________________________________________________________________

(лицензияләүче орган атамасы)

ЛИЦЕНЗИЯ

№ ____ «__» __________ ____ ел.

________________________________________________________________________________

(лицензияләнүче эшчәнлек төре күрсәтелә)

___________________________________________________________________гамәлгә ашыру.

«Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында» федераль законның 12 статьясының 2 өлеше нигезендә лицензияләнүче эшчәнлек төре составында башкарыла торган (күрсәтелә торган) эшләр (хезмәтләр) төре: _______________

________________________________________________________________________________

(эшчәнлекнең тиешле төрен лицензияләү турында нигезләмәдә билгеләнгән эшләр (хезмәтләр) исемлеге нигезендә күрсәтелә)

Әлеге лицензия бирелде _____________________________________________

(тулы мәгълүмат күрсәтелә (булган очракта)

________________________________________________________________________________

(юридик затның тулы һәм (булган очракта) кыска атамасы (шул исәптән фирма исеме), оешу-хокук формасы, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме һәм (булган очракта) атасының исеме, аның шәхесен таныклый торган документның исеме һәм реквизитлары)

Юридик затның (шәхси эшкуарның) төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) _____

________________________________________________________________________________

Салым түләүченең тәңгәллек номеры ___________________________________

(икенче ягы)

Лицензияләнә торган эшчәнлекнең урнашкан урыны һәм төре

________________________________________________________________________________

(лицензияләнүче эшчәнлек төрләре составында эшләрне (хезмәтләрне) башкару (күрсәтү) гамәлгә ашыруның урнашкан урыны (шәхси эшкуарның яшәгән урыны) һәм гамәлгә ашыру урыны адресы күрсәтелә)

Әлеге лицензия түбәндәге срокка бирелде:

┌─┐ ┌─┐
│ │ чикләнмичә │ │ _____ елның «__» ________________ кадәр.
└─┘ └─┘ («Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында» федераль законның 1 статьясының 4 өлешендә күрсәтелгән эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруны җайга салучы федераль законнарда лицензиянең гамәлдә булуының башка чоры күрсәтелгән очракта күрсәтелә)

Әлеге лицензия лицензияләүче органның ____ елның «__» _________ № ______ карары – боерыгы (күрсәтмәсе) нигезендә бирелә

Лицензияләүче органның _____ елның «__» __________ № ______ карары – боерыгы (күрсәтмәсе) нигезендә әлеге лицензиянең гамәлдә булу чоры _____ елның «__» __________ кадәр озынайтылды.

(«Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында» федераль законның 1 статьясының 4 өлешендә күрсәтелгән эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруны җайга салучы федераль законнарда лицензиянең гамәлдә булуының башка чоры күрсәтелгән очракта күрсәтелә)

Әлеге лицензия лицензияләүче органның ___ елның «__» __________ № ______ карары – боерыгы (күрсәтмәсе) нигезендә үзгәртеп рәсмиләштерелде

Әлеге лицензиянең аерылгысыз өлеше булып торган ____ биттә _________ кушымтасы (кушымталары) бар

| | | |
|---|---|---|
| ___________________________ | ___________________________ | _____________________ |
| (вәкаләтле затның вазыйфасы) | (вәкаләтле затның имзасы) | (вәкаләтле затның Ф.И.А.) |

Мөһер урыны

<*> Лицензиядә аның аерылгысыз өлеше (бу хакта тиешле язу теркәлә) булып торган һәм лицензиат турында «Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында» федераль законның 15 статьясында, шулай ук «Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында» федераль законның 1 статьясының 4 өлешендә күрсәтелгән аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү үзенчәлекләрен билгеләүче федераль законнарда каралган мәгълүматларны үз эченә алган кушымталар булырга мөмкин.

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенең
күпфатирлы йортлар белән идарә
итү буенча эшкуарлык
эшчәнлеген лицензияләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
кушымта (белешмәлек)

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгы | 236-91-44 | Sergey.Kraynov@tatar.ru |
| ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары | 236-81-11 | Vagiz.Sattarov.gji@tatar.ru |
| Лицензияләүне гамәлгә ашыручы бүлек хезмәткәре | 590-88-71 | Yulduz.Kashapova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт бүлеге башлыгы | 264-76-02 | Fail.Salihov@tatar.ru |